**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6437**
**30.11.2020**

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 30 ноябрендәге
6437 номерлы карарына
кушымта

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»
муниципаль программасы

# 1. Бүлек. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге УП-312 номерлы Указы, Министрлар Кабинетының «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе |
| Программаның максаты | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның татар, рус һәм башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | 1. Татар һәм рус телләренең Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак бертигез хокуклы эшләвенә ярдәм күрсәтү.<br>2. Татар һәм рус телләрен өйрәнү, татар һәм рус телләрендә укытуның бер бөтен системасын үстерү.<br>3. Татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни һәм фәнни-методик ярдәм күрсәтү.<br>4. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклау һәм үстерү. |

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2020 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | Тормышка ашыруның барлык чорында (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | - | - | - | - | - | - |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2021-2025 еллар |
| Программаның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 1) муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгару;<br>2) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару;<br>3) Россия Федерациясе дәүләт телендә белем алу, шулай ук муниципаль белем бирү оешмалары мөмкинлеге чикләрендә укыту һәм тәрбия бирү телен Россия Федерациясе халыкларының телләре арасыннан сайлау;<br>4) муниципаль оешмалар биналарында ике дәүләт телендә язылган тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын урнаштыруны тәэмин итү;<br>5) урам күрсәткечләрен, муниципаль оешмалар биналарында фасад табличкаларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язуны тәэмин итү;<br>6) этник-тел толерантлыгын формалаштыру. |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет гамәлгә ашыра |

2. бүлек. Программада хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларның эчтәлеге

Яр Чаллы шәһәрендә тел өлкәсендә шәхеснең конституцион хокукларын тормышка ашыру өчен шартлар үтәлә, укучыларны үз туган телендә укыту һәм тәрбияләү өчен кирәкле шартлар булдырылган. Ике дәүләт теленең конституцион статусына максатлы рәвештә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләнә.

Башкарма комитетның мәгариф идарәсе карамагында 129 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бар. Ике мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Гөлназ» 49 нчы МББУ һәм «Көнбагышкай» 82 нче МББУ да белем бирү процессы тулысынча татар телендә оештырылган. Аларда 545 бала тәрбияләнә.

Шәһәрнең 129 МББУда татар милләтеннән 13 934 бала тәрбияләнә, бу МББУ дагы гомуми балалар санының 40,1 % ын тәшкил итә.

Шәһәрнең балалар бакчаларында 1509 төркем эшли, шуларның 354 ендә тәрбия һәм белем бирү – татар телендә (23,4 %).

Тәрбия һәм белем бирү татар телендә булган төркемнәрдә тәрбияләнүчеләрнең саны – 8 359, шуларның 90,1 % ы – татар милләтеннән, 0,3 % ы – катнаш никахтан туган балалар, 0,7 % ы – башка милләтләр.

Татар теле укытыла торган, яңадан комплектлаштырылган төркемнәрдә балаларның 30 % ы гына татар телен югары дәрәҗәдә белә (сөйләмне аңлыйлар, сорауга җавап бирәләр, аралашалар).

Яр Чаллы шәһәренең 78 белем бирү оешмасында 62 428 укучы укый. Милли состав буенча 62 дән артык милләт баласы белем ала. Иң күп сандагылар: руслар – 27 564 (44 %), татарлар – 25 866 (41,4 %), башка милләтләр – 8998 (14,4 %).

Шәһәрдә 11 татар мәктәбе эшли, шуларның 3 се гимназия (2 нче, 29 нчы, 54 нче), ике лицей-интернат (79, 84), предметлар тирәнтен өйрәнелә торган бер лицей (18). 2019-2020 уку елында аларда 8 173 укучы белем алды, шуларның 6 077 се (74,4 %) татар милләтеннән, бу татар милләтеннән булган балаларның гомуми санының 23,4 % ын

тәшкил итә. Шәһәр буенча гомуми балалар санының 8 % ы туган телендә укытыла, татар балаларының 21 % ы туган телдә тәрбияләнә.

Шәһәрнең белем бирү оешмаларында шулай ук татар телендә тәрбия бирә торган сыйныфлар ачыла.

Шәһәр Башкарма комитетының, педагогик җәмәгатьчелекнең милли үзаң булдыру өчен шартлар тудыру буенча системалы эшләве милли белем бирү базасын саклау, поликультуралы мохит моделен үстерү мөмкинлеге бирә.

«Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе базасында туган тел сөючеләрнең 9 клуб берләшмәсе эшли. Әлеге клубларда төрле милләт балалары үз туган халыкларының милли мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм традицияләре, аларның рухи һәм әхлакый кыйммәтләре белән танышалар, туган телләрен өйрәнәләр.

Телләрне үстерүгә мәгълүмат киңлекләре зур йогынты ясый. Соңгы вакытта телләрнең лексика күләме кимү, орфография, пунктуация һәм стилистика хаталарының артуы күзәтелә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында. Яшьләрнең теле чит илдән кергән сүзләр, жаргоннар, вульгаризм һәм компьютер лексикасы сүзләре белән тулды. Дәүләт, ведомство буйсынуындагы һәм муниципаль хакимиятнең барлык дәрәҗәләрендә дә, иҗтимагый оешмаларның актив катнашында, телләрне саклау механизмын эшләү зарур.

Глобальләшү шартларында Россиядә дә, бөтен дөньяда да татарларның мәдәни ассимиляциясе процесслары көчәя, милли үзенчәлек һәм гасырлык традицияләре югала, боларның күрсәткече булып, һичшиксез, татар теле тора. Туган телен белгән татарлар саны кимү тенденциясе саклана. Татар телен белү дәрәҗәсенең кимүе белән беррәттән, татар телен куллану өлкәсенең дә тараюы күзәтелә, шул исәптән халыкның эштә һәм көнкүрештә көндәлек аралашуы шартларында. Бу процесслар татар телендә белем бирүче сыйныфларның саны кимү, урта һөнәри һәм югары белем бирү оешмаларында татар бүлекләренең булмавы, туган татар телендә белем бирү системасының тулы куәткә эшләве өчен сәяси-хокукый һәм институциональ мөмкинлекләр югалу белән бергә бара. Татар халкы тарафыннан туган телне һәм этник мәдәниятне югалту куркынычы татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен саклау, үстерү һәм тарату проблемасының актуальлеген арттыра.

Милли мәгариф һәм тәрбия, барлык яшәеш өлкәләрендә дә татар телен куллануны киңәйтү туган (татар) телне саклауның мөһим факторы булып тора. Әлеге программа, барлык өлкәләрне һәм проблема аспектларын колачлау бөтенлеген, күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген һәм программаның телләрнең яшәвенә бәйле барлык төп факторларга йогынтысының нәтиҗәлелеген тәэмин итәргә тиешле яңа төп принциплардан файдаланып, алдагы программаларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсен анализлау нигезендә эшләнде.

## 3 бүлек. Программаның максаты һәм бурычлары

Программа телләрнең үсешен һәм гармонияле үзара бәйләнештә булуын, республикада яшәүче халыклар вәкилләренең милли-тел мәнфәгатьләренең тотрыклы балансын саклауны күздә тоткан Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп принципларына туры китереп эшләнде.

Программаның максаты – Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның татар, рус һәм башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны тормышка ашыруны күздә тота:

- Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең бертигез хокуклы эшләвенә ярдәм күрсәтү;

- татар һәм рус телләрен өйрәнүнең, татар һәм рус телләрендә укытуның бер бөтен системасын үстерү;

- татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни һәм фәнни-методик ярдәм күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклау һәм үстерү.

4 бүлек. Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм этаплары

| № т/б | Этапның исеме | Тормышка ашыру чоры |
|---|---|---|
| 1 | Программаны тормышка ашыру | 2021-2025 еллар |
| 2 | Йомгак ясау | 2025 елның 4 кварталы |

5 бүлек. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме (мең сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | | | |
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| Барлыгы | - | - | - | - | - | - |

6 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләр

Программаның нәтиҗәлелеге чараларның билгеләнгән срокларда үтәлү дәрәҗәсе буенча бәяләнә. Программаны тормышка ашыру түбәндәге нәтиҗәләрне тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк:

- муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгару;

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару;

- Россия Федерациясенең дәүләт телендә белем алу, шулай ук муниципаль белем бирү оешмалары мөмкинлеге чикләрендә укыту һәм тәрбия бирү телен Россия Федерациясе халыкларының телләре арасыннан сайлау;

- муниципаль оешмалар биналарында ике дәүләт телендә язылган тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын урнаштыруны тәэмин итү;

- урам күрсәткечләрен, муниципаль оешмалар биналарында фасад табличкаларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язуны тәэмин итү;

- этник-тел толерантлыгын формалаштыру.

7 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Эш кәгазьләрен алып баруда Татарстан | $\frac{N}{D} * 100\%$ | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республикасының ике дәүләт телендә башкарылган документлар өлеше, процент | N - эш кәгазьләрен алып баруда Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә башкарылган документларның саны;<br>$D$ - эш кәгазьләрен алып баруда башкарылган документларның гомуми саны | идарәсе |
| 2. | Тышкы һәм эчке визуаль мәгълүматны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язу өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N - Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язылган тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чарасының саны;<br>$D$ – Яр Чаллы шәһәрендәге тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чарасының гомуми саны | Башкарма комитет, муниципаль оешмалар |
| 3 | Урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язу өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N - Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язылган урам күрсәткечләренең саны;<br>$D$ – Яр Чаллы шәһәрендә урам күрсәткечләренең гомуми саны | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| 4 | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Туган тел һәм әдәбият» (татар) предметын сайлауда катнашучылар өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N - «Туган тел һәм әдәбият» (татар) предметын сайлаган укучылар саны;<br>D - татар милләтеннән булган укучыларның гомуми саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, «БАРС. Мәгариф» системасы (статистик хисап) |
| 5 | Мәктәпкәчә оешмаларда балаларны туган татар телендә тәрбияләү һәм укытуны сайлауда катнашучылар өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N – татар төркемнәрендә балалар саны;<br>D – мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә татар милләтеннән булган балаларның гомуми саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, «БАРС. Мәгариф» системасы (статистик хисап) |

8 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, чаралары һәм чараларны финанслау

| № | Чараларның исеме | Башкаручылар | Максат индикаторлары һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Чыганакны күрсәтеп, финанслауның күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| | | | | | | | | | Җирле бюджет | | | | |
| Максат: Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның татар, рус телләрен һәм башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч: Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең бертигез хокуклы эшләвенә ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Мәдәният чараларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару һәм оештыру | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 40 | 45 | 45 | 45 | 45 | - | - | - | - | - |
| 2. | Эш кәгазьләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | Эш кәгазьләре белән эшләүдә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә башкарылган документларның өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 3. | Тышкы һәм эчке визуаль мәгълүматны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язу | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин | Тышкы һәм эчке визуаль мәгълүматны Татарстан Республикасының | 90 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | итү идарәсе | ике дәүләт телендә язуның өлеше, процент | | | | | | | | | | |
| 4. | Урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язу | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә язуның өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 5. | Шәһәр чараларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | - | - | - | - | - |
| 6. | Россия Федерациясе дәүләт телендә белем алу, шулай ук муниципаль белем бирү оешмалары мөмкинлеге чикләрендә укыту һәм тәрбия бирү телен Россия Федерациясе халыкларының телләре арасыннан сайлау | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Телне сайлауда катнашучылар өлеше, процент | 65 | 65 | 66 | 67 | 68 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Россия Федерациясе дәүләт телендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү һәм укыту, шулай ук муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары мөмкинлеге чикләрендә тәрбияләү һәм укыту телен Россия Федерациясе халыкларының телләре арасыннан сайлау | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Телне сайлауда катнашучылар өлеше, процент | 58 | 59 | 59 | 60 | 60 | - | - | - | - | - |
| 8. | «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» республика конкурсында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, МББУ | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | - | - | - | - | - |
| 9. | Рус теле көнен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | - | - | - | - | - |
| 10. | Г.Тукайга багышланган чараларны оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 5000 | 5287 | 6031 | 6474 | 6600 | - | - | - | - | - |
| 11. | Милли спорт төрләре буенча ярышлар һәм турнирлар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 бурыч: Татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм татар һәм рус телләрендә укытуның бер бөтен системасын үстерү | | | | | | | | | | | | | |
| 12. | Шәһәр программаларын туган татар телендә оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Татар телендә программалар саны, берәмлек | 4 | 5 | 5 | 5 | 5 | - | - | - | - | - |
| 13. | Мәктәп яшендәге балаларны туган телдә укыту һәм тәрбияләү буенча Интернет ресурслар эшләү буенча конкурс оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, берәмлек | 64 | 64 | 64 | 64 | 64 | - | - | - | - | - |
| 14. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту һәм тәрбияләү буенча Интернет ресурслар эшләү буенча конкурс оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, берәмлек | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 15. | Татар, рус телләре буенча олимпиадалар оештыру һәм үткәрү (мәктәп һәм муниципаль турлар), татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты буенча республика турында һәм халыкара олимпиадада катнашуны тәэмин итү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | - | - | - | - | - |
| 16. | Республика фәнни-практик конференцияләренең, педагогик укуларының муниципаль турларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17. | Туган тел укытучылары өчен Бөтенроссия «Туган тел» конкурсы мастер-классының муниципаль турын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 | - | - | - | - | - |
| 18. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында «1-4 сыйныфларда туган (татар) телдә иң яхшы укыту практикасы» муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 | - | - | - | - | - |
| 19. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында «Туган (татар) телдә иң яхшы тәрбия бирү практикасы» муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | - | - | - | - | - |
| 3 бурыч: Татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни һәм фәнни-методик ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | | | | |
| 20. | Татар һәм рус телләре укытучылары өчен укыту семинарлары оештыру һәм үткәрү, региональ киңәшмәләрдә, семинарларда катнашу | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | - | - | - | - | - |
| 21. | Балаларны татар телендә | Башкарма | Катнашучылар | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | укытучы тәрбиячеләр өчен укыту семинарлары оештыру һәм үткәрү, региональ киңәшмәләрдә, семинарларда катнашу | комитетның мәгариф идарәсе | саны, кеше | | | | | | | | | | |
| 4 бурыч: Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | | | | |
| 22. | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында халыкара Туган тел көненә багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 57 | 60 | 65 | 65 | 65 | - | - | - | - | - |
| 23. | Туган тел сөючеләр клубы челтәрен саклау | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | - | - | - | - | - |
| 24. | Туган телдә һәм төрле халыкларның телләрендә сәнгатьле уку конкурсларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 180 | 180 | 180 | 180 | 180 | - | - | - | - | |
| 25. | «ЖырлаОке» шәһәр музыкаль конкурсы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | - | - | - | - |
| 26. | Заманча татар мәдәнияте | Башкарма | Катнашучылар | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фестивале (Open air креатив индустрия) | комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | саны, кеше | | | | | | | | | | |
| 27. | «Дуспочмак» кунакханәсе» шәһәр конкурсы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 200 | 200 | 200 | 200 | 300 | - | - | - | - | - |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева